**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЯСЕ**

| **«КАРАЛДЫ»** | **«КИЛЕШЕНДЕ»** | **«РАСЛАНДЫ»** |
|---|---|---|
| Методик берләшмә җитәкчесе<br>__________Замалиева И.Х.<br>МБ утырышы беркетмәсе<br>№1 25 август 2016 ел | Директор урынбасары<br>________Л.Р.Ягудина<br><br>27 август 2016 ел | Мәктәп директоры<br>________Л.Н.Липлянина<br>Педагогик совет беркетмәсе<br>233 нче номерлы боерык белән гамәлгә кертелде.<br>31 август 2016 ел |

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Чибинова Лилия Рәис кызы
10 «а» сыйныфы өчен татар теленнән
эш программасы

Педагогик киңәшмә
Утырышында каралды.
Беркетмә №1
31 август 2016 ел

**2016 - 2017**

**1.Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.**

**Сыйныф**: 10-а
**Укытучы:** Чибинова Л.Р.
**Уку планы буенча татар теленнән:***35 сәг.*
**Атнага:***1сәг.*
Тест:3
Инша:1
**Административ контроль эш-1**
**Диктант-2**
**Дәреслек -**. Татарча да яхшы бел. Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныф өчен татар теле дәреслеге (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). Авторы: Р.Р. Нигъмәтуллина. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 2011ел.
Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:
1.Программа: Татарстан РеспубликасыМәгарифһәмфәнминистрлыгы. Урта (тулы) гомумибелембирүмәктәбендәрустеллебалаларга татар теленкоммуникатив технология нигезендәукытупрограммасы (1 — 11 нчесыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.
2.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында урта гомуми белем бирү программасы.
3.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомумибелемучреждениясе “Аерымпредметларнытирәнтенөйрәнүче Алексеевск 2 нчеуртагомумибелеммәктәбе”нең 2016-2017укуелынаукытупланы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016
Татар теле укытуның максаты:

- укучыларның үзләштергән белемнәрен һәм сөйләм күнекмәләрен камилләштерү;

- татар теленең орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик нигезләрен системалы рәвештә өйрәнү;

-укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилләргә күнектерү;

-укучыларда тел сиземләү күнекмәләре булдыру;

-татар теленең башка телләр арасындагы урыны, татар дөньясы турында мәгълүмат бирү;

-халыкларның үзара аңлашып һәм хезмәттәшлек итеп яшәвенә омтылыш тәрбияләү;

Бурычлар.

Гамәли максатка ирешү өчен,укучыларда татар сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләрен булдыру; диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү; төрле жанрдагы татар текстларын аңлап укуга өйрәтү; дөрес язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен булдыру; татар теленең фонетик, орфоэпик, лексик, грамматик нигезләрен һәм үзенчәлекле тел күренешләрен гамәли үзләштерү. Контроль төрләре.

Укучыларга татар теленнән системалы белем бирү өчен түбәндәге контроль төрләре кулланыла:

контроль эшләр, мөстәкыйль биремнәр, тестлар, карточкалар белән эш,ситуатив күнегүләр һ.б.

Татар теле дәресләрендә лексик материалны истә калдыру, грамматик материалны үзләштерү, бирелгән темаларга хат язу,хикәя, диалог, монологлар төзи белү,тыңлап аңлау күнегүләре өстендә эш алып барыла.

Педагогик технологияләр.

Үстерешле укыту технологиясе.

Күмәкләшеп укыту технологиясе

Проблемалы укыту технологиясе

Коммуникатив укыту технологиясе.

Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр

1.Татар теленең төп фонетик үзенчәлекләрен гамәли белү.

2. Татар телендә сүз басымының үзенчәлекле очракларын белү һәм аерым грамматик формалардагы сүзләргә басымны дөрес куя белү.

3. Кушма, тезмә, парлы һәм кыскартылма сүзләрне дөрес куллана һәм яза белү.

4. Антоним, синоним, омонимнарны аера белү һәм сөйләмдә урынлы куллана алу.

5 Татарча-русча, русча-татарча һәм башка төрле сүзлекләрдән файдалана белү.

6. Лексик берәмлекләрнең күчерелмә мәгънәләрен,башкасүзләр белән бәйләнешкә керү үзенчәлекләрен белү.

7. Аерым сүз төркемнәренә хас грамматик формаларның татар һәм рус телләрендә тәңгәл килү-килмәвен белү.

8. Җөмләдә сүзләрне бәйләүче чараларны гамәли куллана белү.

9. Иярченле кушма җөмләләрнең аналитик һәм синтетик төрләрен гамәли куллана белү.

10. Бер үк фикерне төрле синтаксик калыплар белән белдерә алу.

11. Язма сөйләмдә тыныш билгеләрен дөрес куя белү: ия белән хәбәр арасында сызык; җөмләнең аерымланган кисәкләре, модальсүзләр, тиңдәш кисәкләрянында, кушма җөмләдә тыныш билгеләре (өтер, ике нокта, сызык ).

Уку

- Программада тәкъдим ителгән текстларны, татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;

- текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү;

- таныш булмаган текстны эчтән укып, аның төп фикерен таба белү;

- таныш булмаган сүзләрнең, төзелмәләрнең тәрҗемәсен сүзлектән таба белү.

Язу

- өйрәнелгән темалар буенча актив куллануда булган сүзләрне дөрес яза белү;

- конкрет бер тема буенча хикәя төзи белү;

- прагматик текстлар ( рецептлар, белдерүләр, афиша һ.б.), эпистоляр жанры текстлары (хатлар, котлаулар) яза белү;

- үзеңне борчыган темага карата фикерләреңне язмача җиткерә белү;

- тәкъдим ителгән текстның эчтәлегенә нигезләнеп, аны үзгәртеп яки дәвам итеп яза белү

1. Җөмләләрнең баш һәм иярчен кисәкләренең исемнәрен әйтә, сорау куя, аера белү.

2. Кушма һәм гади җөмләләрне аера белү.

3. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрне сөйләмдә куллана белү күнекмәләрен булдыру.

4. Җыючы, каршы куючы, бүлүче теркәгечле кушма җөмләләрне сөйләмдә куллану.

5. Иярчен хәл җөмләләрнең иярчен вакыт җөмлә, урын җөмлә, рәвеш җөмлә, күләм җөмлә, максат җөмлә, шарт җөмлә, сәбәп җөмлә, кире җөмләләрен танып белү һәм аларны сөйләмдә урынлы куллануга ирешү.

6. Тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес кую һәм аларны тиешле интонация белән әйтә белү

Тыңлап аңлау

Төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү;

сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;

зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне, информацион характердагы текстларны, газета-журналлардан мәкаләләрне тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралашуга чыга белү;

Сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

Диалогик сөйләм

Сорау, җавап, килеш(мә)ү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору, сөйләшә белү;

аралашуда катнаша, аны туктата һәм яңадан башлый белү;

парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү;

терәксхемаларкулланып, ситуация буенчаәңгәмә кора белү;

татар сөйләм этикеты үрнәкләреннән урынлы файдаланып әңгәмә кору, сөйләшә белү.

Монологик сөйләм

Программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә текст төзи һәм аның эчтәлеген сөйли белү;

конкрет ситуациягә үз карашыңны, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү;

монологик сөйләмдә кереш, эндәш сүзләрне кулланып, орфоэпик һәм грамматик нормаларны саклап, үз фикереңне төгәл җиткерә белү;

өйрәнгән текстны үз сүзләрең белән сөйләп бирә белү;

өйрәнгән шигырьләрне яттан сәнгатьле сөйли белү

Контроль төрләре.

Укучыларга татар теленнән системалы белем бирү өчен түбәндәге контроль төрләре кулланыла:

контроль эшләр, мөстәкыйль биремнәр, тестлар, карточкалар белән эш,ситуатив күнегүләр һ.б.

Татар теле дәресләрендә лексик материалны истә калдыру, грамматик материалны үзләштерү, бирелгән темаларга хат язу,хикәя, диалог, монологлар төзи белү,тыңлап аңлау күнегүләре өстендә эш алып барыла

| |
|---|
| Белем һәм тормыш. ( 11 сәг.)<br><br>Киләчәккә сайлаган юл. Теләк һәм мөмкинлекләр. Казандагы югары уку йортлары. Төрле телләр өйрәнү кирәклеге. |
| Дустың булмаса эзлә, тапсаң сакла. ( 12 сәг.)<br><br>Дустым, аның уңай һәм тискәре сыйфатлары, яхшы һәм начар гадәтләре, дус була белү, дуслар белән аралашу серләре. |
| Саф хисләр, беренче хисләр... ( 11 сәг.) Кызлар-егетләр дуслыгы, үзара аралашу әдәбе. Саф хисләр, беренче хисләр, аларга сак караш. |

## II.Укыту предметының эчтәлеге

Укучыларның яшь үзенчәлекләре буенча кызыксынуларын, аралашу ихтыяҗларын, психо-физиологик мөмкинлекләрен исәпкә алып сайлана; төп универсаль уку гамәлләрен үстерүгә, аларда шәхси кыйммәтләр формалаштыруга хезмәт итә.

Программада һәм дәреслектә бирелгән темалар эчтәлеге буенча бераз аерыла . Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасында әйтелгәнчә, укытучылар мәктәпнең эш үзенчәлеген, укучыларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, уку материалын өйрәнүгә сәгатьләр саны бүленешен һәм материалны өйрәнү эзлеклелеген билгеләүдә, эчтәлекне киңәйтүдә, шулай ук укучыларның коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру юлларын ачыклауда эш программасына үзгәрешләр кертә алалар.

1. Татар теленең һәм әдәбиятының дөньякүләм тоткан урыны турында мәгълүмат бирү.

2. Татар һәм рус телләрендәге аерым грамматик категорияләрнең тәңгәл килү-килмәвен белү;

3. Татар теленең орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик, пунктицион нормаларын белү һәм, аларга нигезләнеп, телдән яки язма сөйләм күнекмәләрен булдыру;

4. Аралашу ситуацияләренә бәйле лексик берәмлекләрне, аларның синонимнарын һәм антонимнарын төгәл һәм урынлы куллана белү;

5. Татар теленең фразеологик берәмлекләрен таный һәм сөйләмдә куллана белү;

6. Татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуын белеп, оештыру осталыгына ия булу;

7. Төрле чыгаганаклардан (фәнни-популяр текстлар, массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет һ.б.) файдаланып, кирәкле мәгълүматны таба һәм башкаларга телдән яки язмача җиткерә алу;

8. Мәдәниара аралашу ситуацияләрендә әңгәмә кора алу;

9. Тиешле күләмдә татар сүзләрен яттан белеп, аларны телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллана белү.

**10-11 нче сыйныфлар**

| | Эш төрләре | Сыйныфлар | |
|---|---|---|---|
| | | 10 | 11 |
| 1. | Тыңлап аңлау | 1,5-2,0 минут | 2-2,5 минут |
| 2. | Диалогик сөйләм | 11-12 реплика | 13-14 реплика |
| 3. | Монологик сөйләм | 10-12 фраза | 12-14 фраза |
| 4. | Һәр тема буенча аралаша белү күнекмәләрен ситуатив күнегүләр аша тикшерү | 5 | 5 |
| 5. | Уку | 95-100 сүз | 95-100 сүз |
| 6. | Язу: | | |
| | сүзлек диктанты | 25-27 сүз | 28-30 сүз |
| | сочинение | 12-15 җөмлә | 13-15 җөмлә |

## III.Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру.

| № | Дәреснең темасы | Уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Киләчәккә минем сайлаган юлым | Мәктәп турында сөйләргә (монологик сөйләм) | 2.09 |
| 2 | Казан дәүләт университеты | Индив. карточкалар куллану | 9.09 |
| 3 | **Фән исемлеге. Кереш тест №1** | Авторлык эше. | 16.09 |
| 4 | Хаталар өстендә эш.Теләсә... грамматик конструкциясе Н.И.Лобачевский исемендәге китапханә | Сорау җөмләләр төзү | 23.09 |
| 5 | Төрле телләр өйрәнү кирәклеге | Сорауларга җавап бирү | 30.09 |
| 6 | Чит илләрдәге татарлар тормышы | Рәсем буенча сөйләү | 7.10 |
| 7 | Сыйфатлар | Үрнәк буенча сөйләү | 14.10 |
| 8 | **Тест №2 “Белем һәм** | Р.З.Хәйдәрова Г.М. Әхмәтҗанова.Яр.Чаллы.2014. 96. | 21.10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **тормыш”** | | |
| 9 | Хаталар өстендә эш.<br><br>*өчен* бәйлеге | Төркемнәрдә эшләү | 28.10 |
| 10 | Мәктәп формасы тарихы | Сорауларга җавап бирү | 11.11 |
| | **Тема: Дустың булмаса эзлә, тапсаң сакла (Кешене кием генә бизиме?) - 5сәг.** | | |
| 11 | Ягымлы сүзләр. | Рәсемгә карап сөйләү | 18.11 |
| 12 | Кеше сыйфатлары. | Үрнәк буенча сөйләү | 25.11 |
| 13 | Кемнең нишлисе килә? Кемнең нишлисе бар? | Таблица буенча сөйләү | 2.12 |
| 14 | **Диктант.”Чык суы”** | Диктант | 9.12 |
| 15 | Хаталар өстендә эш. Дуслар белән аралашу серләре | Сорауларга җавап бирү | 16.12 |
| | **Тема:Саф хисләр, беренче хисләр (Матур кеше нинди була?) - 6 сәг.** | | |
| 16 | Кызлар – малайлар дуслыгы | Рәсемгә карап сөйләү | 23.12 |
| 17 | Беренче хисләр | Парлап эшләү | 13.01 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 18 | Нишләгәннән соң? | Төркемнәрдә эшләү | 20.01 |
| 19 | ...*килә* ярдәмче фигыле. | Сорауларга җавап бирү | 27.01 |
| 20 | **Сочинение.”Минем хыялдагы мәхәббәтем”** | Үрнәк сочинениеләр. | 3.02 |
| 21 | Хаталар өстендә эш.<br><br>Фигыль формалары | Индив. сорау | 10.02 |
| **Тема: “Шушы яктан, шушы туфрактан без...” – 7 сәг.** | | | |
| 22 | Хикәя, сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләр. | Төркемнәрдә эшләү | 24.02 |
| 23 | Хәл фигыльнең -ганчы\гәнче формасы | Сорауларга җавап бирү | 3.03 |
| 24 | Татар халкы тарихы.<br><br>**Сүзлек диктанты.** | Р.З.Хәйдәрова. Г.М. Әхмәтҗанова. Яр.Чаллы. 2014 .85 бит. | 10.03 |
| 25 | Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары | План бенча кыскача сөйләү | 17.03 |
| 26 | Татарстанның сынлы сәнгате | Рәсемнәр буенча фикер алышу | 31.03 |
| 27 | **Тест №3 “Саф хисләр , беренче хисләр”.** | Р.З.Хәйдәрова. Г.М. Әхмәтҗанова. Яр.Чаллы. 2014. 101.бит | 7.04 |
| 28 | Хаталар өстендә эш. Татарстанда яшьләр хәрәкәте | Хәл фигыль формаларын аңлап куллану | 14.04 |
| | **Тема: Зарарлы гадәтләрдән сакланыгыз! (Сәламәтлек – зур байлык) – 7 сәг.** | | |
| 29 | Сәламәтлек – | Парлап эшләү | 21.04 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | үзе бер бәхет | | |
| 30 | Зарарлы гадәтләр, алардан ничек котылырга | Карточкалар куллану | 28.04 |
| 31 | Модага ияреп киенү һәм сәламәтлек | Сорауларга җавап бирү | 5.05 |
| 32 | **Административ контроль эш.** | Карточкалар белән инд.эш | 12.05 |
| 33 | Хаталар өстендә эш | Хаталарны төзәтү. | 12.05 |
| 34 | Күнегүләр өстендә эш | Индив. биремнәр | 19.05 |
| 35 | Йомгаклап кабатлау дәресе | Сүзлек запасын баету өстендә эшләүне дәвам итү | 26.05 |

Пронумеровано,прошнуровано

11 (одиннадцать)

Учитель татарского языка и литературы

Чибинова Лилия Раисовна